**Республика Татарстан**
**Сармановский муниципальный район Карашай Сакловское сельское поселение**
**423378 ул.Ленина д.100 с.Карашай Саклово Телефон: 885559 4-92-18**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай Саклау авыл жирлеге**
**423378 ,Карашай Саклау авылы, Ленин ур.100 йорты Телефон: 885559 4-92-18**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
« 04 » ноябрь 2024 ел № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Карашай-Саклау авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы нигезендә. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Уставы:

1.Карашай-Саклау авылы мәдәният йорты бинасында, гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 15 нояберенә 9 сәгать 00 минутта билгеләргә

2.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:«I группа инвалидлар , көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, 2025 елда 600 сум үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкаруга тоту белән килешәсезме:

1. Карашай-Саклау торак пунктларын төзекләндерү ,халыкның күпләп ял итү урыннарын кору (Сабантуй милли бәйрәмен үткәрү урынын койма белән әйләндереп алу һәм төзелеш материаллары сатып алу, «Хәтер бакчасы» паркын койма белән әйләндереп алу өчен әзер коймалар сатып алу ) ;

2. Карашай-Саклау авылындагы махсус күмү урыннарын төзекләндерү (биек агачларны йолкыту, куаклардан чистарту очен махсус аренда.техника яллау )

3. Карашай-Саклау торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау;

4. Карашай Саклау авылында көнкүреш калдыклары, чүп-чарлар вакытлыча җыела торган урыннарны җыештыру һәм чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен килешү буенча түләү, махсус техника яллау )

«ӘЙЕ» «ЮК?».

3.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, Чураш авылы торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Карашай-Саклау Советы Башлыгы

авыл җирлеге Башлыгы В. В. Хөсниева